2024 нче елның 29 нчы августында
үткән педагогик киңәшмәдә расланды.
Беркетмә № 1.
Педсовет рәисе Э.А.Нургалиева
Балалар бакчасы мөдиренең нче номерлы
приказы нигезендә гамәлгә керде
Балалар бакчасы мөдирә Э.А.Нургалиева

«ЯНУРУСОВСКИЙ ДЕТСКИЙ САД»
ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ИНН 1636003464

# Сарман муниципаль районы Янурыс авылы балалар бакчасының 2024-2025 нче уку елына укыту-тәрбия планы.

Янурыс авылы- 2024

# Планның эчтәлеге....................................2

**1.Кереш**..........................................................................................3
-Анализ..........................................................................................3-5
-Максат, төп бурычлар........................................................................6

**2. Белем турында законнар үтәлеше**....................................................7

**3. Кадрлар белән эшне оештыру**............................................................8
-Кадрлар арасында эш бүленеше..........................................................8
-Тәрбиячинең үз белемен күтәрү темасы.............................................8
-Педагогларның һөнәри квалификациясен күтәрү................................8
-Алдынгы педагогик тәҗрибәне гомумиләштерү, тарату......................8
-Консультация, әңгәмәләр....................................................................9
-Ачык шөгыльләр.................................................................................9

**4.Укыту-тәрбия эшеняхшыртуга юнәлдерелгән эшчәнлек**
-Педагогик киңәшмәләр.......................................................................10
-Укыту-тәрбия процессында педагогик контроль..................................11
-Метод почмакта эш............................................................................12
-Смотр-конкурслар, күргәзмәләр.........................................................12-13
-Бәйрәмнәр, күңел ачу кичәләре...........................................................13

**5.Ата-аналар белән эш**.....................................................................14-16

**6.Җәмәгатьчелек һәм спонсорлар белән эш**........................................16

**7.Административ-хуҗалык эшләре**.....................................................17

**8.Балалар бакчасының сәламәтләндерү планы**.....................................18-19

**9.Балалар бакчасының мәктәп белән элемтә планы**..............................20

<u>1 нче бүлек</u>

Кереш өлеш.

Янурыс авылы балалар бакчасының
2023-2024 нче уку елы эшенә анализ.

Янурыс авылы балалар бакчасында 2023-2024 нче уку елында 5 бала белем һәм тәрбия алды. Уку елында балалар бакчасы тулысынча кадрлар белән тәэмин ителде.
**Бакча мөдире:** Нургалиева Эльмира Әзһәм кызы, югары белемле, пед. эш стажы- 17 ел.
**Тәрбияче:** Мавлавиева Фәния Геннадий кызы, югары белемле, пед. эш стажы- 15 ел.

Балалар бакчасы 2023-2024 нче уку елында түбәндәге бурычларны үз алдына куеп эшләде:
1. Федераль дәүләт белем бирү стандартларын гамәлгә ашыру кысаларында нәтиҗәле белем бирү технологияләрен кулланып балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү сыйфатын тагын да камилләштерегә.

2.Балалар бакчасы һәм гаиләнең хезмәттәшлеген арттырырга, балалар бакчасының гаилә белән эшчәнлегендә яңа алымнар кулланып эшләргә.

3. Тәрбия һәм белем бирү процессын иҗади оештырырга. Балаларның эшчәнлегенең төрле формаларын киң кулланырга: укыту һәм тәрбия процессының нәтиҗәлелеген күтәрү максатыннан аларны камилләштерергә, балаларны мәктәпкә әзерләргә.

4.Балаларны республиканың дәүләт телләренә, туган телгә өйрәтү өчен методик базаны камилләштерергә.

Бу бурычларны тормышка ашыру максатыннан ел башыннан ук эш планы кабул ителде һәм план нигезендә ел дәвамында эш оештырылды.

Балалар бакчасының төп максаты:
Балада белем алуга кызыксыну тудыру, аның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, дәресләрне яңа технологияләр, үтемле һәм нәтиҗәле чаралар кулланып, программа таләпләренә туры килерлек итеп үткәрү.

Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү эше түбәндәге программалар һәм методик кулланмаларны кулланып башкарылды:

1. «Образовательная программа» воспитательно-образовательной работы МБДОУ «Янурусовский детский сад».

2. Примерная программа “От рождения до школы” Н.Е.Вераксы, М.А.Васильевой, Т.А.Комаровой
3. “Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы” Р.К. Шаехова.
4. «Туган телдә сөйләшәбез» Зариповой З.М., Гафаровой С.М., Хазратовой Ф.В., 2012.

Тәрбия - белем бирүдә педагог программаның барлык юнәлешләрен (социаль-коммуникатив, сөйләм үстерү, танып белү, нәфис-нәфасәти үсеш, физик үсеш) гамәлгә ашыру өчен бөтен көчләрен куйды. Киләчәктә эшне тагын да камилләштерү өчен балалар бакчасында бөтен мөмкинлекләр бар. Уку елы ахырына тәрбияче үзенең иҗади эшләре, балаларга ясалган диагностикалар нәтиҗәсенең тиешле дәрәҗәдә булуларына ирешәте.
Балалар бакчасында татар балаларына рус теленә өйрәтү С.М.Гаффарованың “Изучаем русский язык” программасы нигезендә алып барыла.

Уку елы дәвамында 4 педагогик киңәшмә үткәрелде. Бу киңәшмәләрдә балаларның физик, психик, социаль үсешенә кагылышлы актуаль мәсьәләләр һәм кече яшьтәге балаларның бакчага ияләшү соруалары, физик сәламәтләндерү эшләрен һәм халык традицияләренә , милли гореф-гадәтләренә нигезләнеп, әхлакый хисләр тәрбияләүне оештырулар, ФГОС таләпләренә туры китереп тәрбия-белем бирү эшен яңартулар каралды. Боларны куллану өчен 3 ноутбук, 1 экран,1 мультимедейный аппаратура, интерактив такта бар, күрсәтмәлелекләр ламинадландырылып бетерелде, төркемдә әти-әниләр өчен стендлар булдырылды, татар телендә мультфильмнар карау оештырылды, перспектив һәм көндәлек планнар системалаштырылды. Балалар бакчасының төркем бүлмәсе һәм үсеш тирәлеге шушы программаларның таләпләренә туры килерлек итеп яңартылды.

Балалар бакчасында әти-әниләр белән эш төрле формаларда алып барылды: анкеталар үткәрелде, актуаль темаларга консультацияләр бирелде, стендлардагы мәгълүматлар тулыландырылды, бердәм бәйрәмнәр, күңел ачулар үткәрелде. Әти-әниләр белән бергә 3 җыелыш үткәрелде.
Ата-аналар белән дустанә мөнәсәбәтләрдә эшләү, аларның ихтирамын яулап, уртак максатлар белән тәрбия һәм белем бирү- тәрбиячеләрнең зур җиңүе ул. Ата-аналарның бердәмлеге, аларның тәрбиячегә карата ихтирамы зур көчкә ия. Башкаларның омтылышларына битараф калмыйча, үзара ярдәмләшеп, аңлашып эшләвебез белән күп нәрсә отабыз. Һәрдаим ата-аналарның ихтирамын тоеп, аларның ярдәменә таянып эшлибез. Ата-аналарның балалар бакчасы белән элемтәсен ныклы итү, аларны һәрвакыт кызыксындырып тору, баланың бакчада нинди тәрбия һәм белем алуына битараф булмыйча, үзләреннән дә зур өлеш кертеп, тәрбияне бербөтен итү өчен бердәм көч куюны максат итеп алдык. Бүгенгәчә шул юлдан тайпылмыйча, ата-аналарны борчыган мәсьәләләрне уртага салып эшләргә тырышабыз.

Балаларны сәламәт рухта тәрбияләү – балалар бакчасының изге бурычы, чөнки балаларның күп вакыты бакчада уза, ул аларның икенче өе булып тора. Шунлыктан бакчада нәниләр өчен барлык уңай шартларны тудырырга тырыштык. Тәрбиячебез көндәлек режимны төгәл үтәп, белем-тәрбия бирү эшен дөрес

оештырды. Иртәнге гимнастика, физкультура занятиеләре ел буена программага нигезләнеп, тиешле дәрәҗәдә алып барылды. Бу юнәлештәге эшнең нәтиҗәсе ата-аналардан да бәйле. Без аларга сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру принципларын өй шартларында да үтәү кирәклеген искәртеп тордык.

Бакчада ел буена көндәлек режим төгәл үтәлде, йоклар алдыннан аяк- кулларны юу, йокыдан торгач балаларның күңелен күтәрү, чыныктыру күнегүләре эшләтелде. Һәр төркемдә буш вакытларда даими рәвештә күз гимнастикасы, аваз әйтү гимнастикалары кертелде. Кыш көне шуар өчен бакча ишегалдында балалар белән бергәләшеп кардан тау ясап куйдык. Дөрес туклану, көндәлек режимны, сәламәтлек программасын төгәл үтәү, физкультура, спорт белән даими шөгыльләнү, организмны чыныктыру балаларыбыз сәламәтлегенә уңай тәэсир итте:алар азрак авырды.
Милли һәм бакча традициясенә әйләнгән бәйрәмнәргә дә зур игътибар бирелде, чөнки милли үзаң, милләткә мәхәббәт хисләренә дә нигез мәктәпкәчә белем бирү учреждениеларында салына. Октябрьдә "Сөмбелә" бәйрәме уздырдык. Декабрь аенда Яңа ел бәйрәменә әзерлек барды һәм бәйрәмне һәр елдагыча бик күңелле итеп үткәрдек. Мартта һәр елдагыча зурлап, ныклы әзерлек белән, Әниләр бәйрәме үтте.

Баланы дөрес сөйләргә өйрәтү, аның сүз байлыгын арттыру, үз фикерен башкаларга ачык , аңлаешлы итеп сөйләргә өйрәтү балалар бакчасының төп бурычы булып тора. Без даими рәвештә шул юнәлештә эш алып барабыз. Моның өчен без ана телендә мультфильмнар карыйбыз, хикәяләр, әкиятләр укыйбыз һәм балалар белән бергә эчтәлеген сөйләп карыйбыз,сюжетлы-рольле, хәрәкәтле һәм түгәрәк уеннар уйныйбыз. Җырлар өйрәнәбез , шигырьләр ятлыйбыз. Картиналар буенча хикәяләр төзергә өйрәнәбез. Сәнгатьле сөйләм, кычкырып уку, хикәя төзеп сөйләү кебек эшләрне башкарганда авазларны дөрес әйтү беренче урынга куела.
Шулай ук балаларның яшь үзенчәлекләрен искә алып, аларның экология өлкәсендә белемнәрен тирәнәйтү, экологик күзаллауларын киңәйтү һәм төгәлләштерү, төп экологик төшенчәләр формалаштыру да төп бурычларның берсе иде. Табигать белән танышып, тирә- юньдәге һәрнәрсәне сакларга өйрәтү, кечкенәдән үк кешенең табигать баласы һәм табигатьнең бер өлеше булуын, табигатьтә һәрнәрсәнең үзара бәйләнештә булуын аңлату, бер-берсе белән тыгыз элемтәдә торуын төшендерү күздә тотылды.
Балалар бакчасы башлангыч мәктәп белән тыгыз элемтәдә тора. Төрле чаралар мәктәп балалары белән берлектә үткәрелә.
Район семинарларында катнашып алдынгы эш тәҗрибәсе өйрәнелде, район балалар бакчаларында ачык дәресләрдә тәҗрибә тупланылды.
Нәтиҗә ясап, шуны әйтәсе килә: коллектив куйган бурычларны үтәү өчен бик тырышып эшләде.

**Максат:**

Балада белем алуга кызыксыну тудыру, аның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, дәресләрне яңа технологияләр, үтемле һәм нәтиҗәле чаралар кулланып, программа таләпләренә туры килерлек итеп үткәрү.

**2024-2025 нче уку елына төп бурычлар:**

1. Федераль дәүләт белем бирү стандартларын гамәлгә ашыру кысаларында нәтиҗәле белем бирү технологияләрен кулланып балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү сыйфатын тагын да камилләштерегә.

2.Балалар бакчасы һәм гаиләнең хезмәттәшлеген арттырырга, балалар бакчасының гаилә белән эшчәнлегендә яңа алымнар кулланып эшләргә.

3. Тәрбия һәм белем бирү процессын иҗади оештырырга. Балаларның эшчәнлегенең төрле формаларын киң кулланырга: укыту һәм тәрбия процессының нәтиҗәлелеген күтәрү максатыннан аларны камилләштерергә, балаларны мәктәпкә әзерләргә.

4.Балаларны республиканың дәүләт телләренә, туган телгә өйрәтү өчен методик базаны камилләштерергә.

2нче бүлек

# Белем турында законның үтәлеше

***Педагогик эшне оештыру***

| № | Чаралар | Вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1. | Балалар бакчасының укыту-тәрбия планын төзү. | август | мөдир |
| 2. | Белем һәм тәрбия бирү өчен кирәк – яракларны җитәрлек күләмдә булдыру. | август | мөдир |
| 3. | Белем һәм тәрбия бирүдә тиешле шартлар булдыру. | даими | мөдир |
| 4. | Балаларның туклануын югары дәрәҗәдә оештыру. | даими | мөдир |
| 5. | Льготаларга ия булган гаиләләрнең исемлеген булдыру. | сентябрь | мөдир, тәрбияче |
| 6. | Балалар бакчасының көндәлек режимын, шөгыльләр челтәрен төзү, раслау. | сентябрь | мөдир, тәрбияче |
| 7. | Балалар бакчасы һәм әти-әниләр арасында килешүләр төзү. | ел барышында | мөдир, тәрбияче |
| 8. | Эвакуация планын барлык эшчеләргә җиткерү, бүлмәләр буенча җаваплы кешеләр билгеләү. | сентябрь | мөдир |
| 9. | Инвентаризация үткәрү. | октябрь | мөдир |
| 10. | Балаларның күңел ачу кичәләрен оештыру. | план буенча | тәрбияче |
| 11. | Балаларның иминлеген һәм хезмәтне саклау инструкциясе үткәрү. | кварталга бер тапкыр | мөдир |
| 12. | Бакчада эшчеләрне, аларның балаларын сәламәтләндерү буенча эш. | даими | мөдир |
| 13. | Балалар бакчасы, шифаханә һәм СЭС белән килешеп, балаларның исәнлеген, сәламәтлеген саклау өчен шартлар тудыру. | даими | мөдир |
| 14. | Яңа уку елына бакчага килүче балаларның төгәл исемлеген булдыру. | май | мөдир, тәрбияче |

3 бүлек.

## Кадрлар белән эшне оештыру.

### 3.1. Кадрлар арасында эш бүленеше.

| № | Ф.И.О. | Вазыйфасы | Эш сәгатьләре |
|---|---|---|---|
| 1. | Нургалиева Э.А. | мөдир | 7.00-12.12, 14.00.-16.00. |
| 2. | Мавлавиева Ф.Г. | тәрбияче | 7.00.- 14.12. |

### 3.2. Тәрбияченең үз белемен күтәрү темасы.

| Алынган тема | Ф.И.О. |
|---|---|
| Кече яшьтәге балаларның сөйләм телен үстерү, балаларга кече яшьтән милли тәрбия бирү. | Мавлавиева Ф.Г. |

### 3.3. Педагогларның һөнәри квалификациясен күтәрү.

| № | Эш төре | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | ФДББС буенча белемнәрне күтәрүне дәвам итү | План буенча | Нургалиева Э.А. |

### 3.4. Алдынгы педагогик тәҗрибәне гомумиләштерү, тарату.

| № | Эшләнәчәк эшләр | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | Район методик берләшмә утырышларында катнашу. | План буенча | Нургалиева Э.А. Мавлавиева Ф.Г |
| 2 | Район ара үткәреләчәк семинарларда катнашу, чыгышлар ясау. | План буенча | Нургалиева Э.А. Мавлавиева Ф.Г |

### 3.5. Консультация, әңгәмәләр.

| № | Тема | Җаваплы кеше | Вакыт |
|---|---|---|---|
| 1 | “Нәниләр төркеме балаларының адаптация үзенчәлекләре” | мөдир, тәрбияче | сентябрь |
| 2 | Балаларның диагностика нәтиҗәләре буенча әңгәмә | мөдир, тәрбияче | сентябрь, май |
| 3 | Сюжетлы-рольле уеннарны яңа заман таләпләренә туры килерлек итеп җиһазлауны дәвам итү. | мөдир, тәрбияче | ноябрь |
| 4 | “Балалар бакчасы һәм гаилә арасында хезмәттәшлек” | мөдир, тәрбияче | февраль |
| 5 | “Сөйләмне үстерү – грамотага өйрәтүнең төп баскычы” | тәрбияче | апрель |
| 6 | “Баланың җәйге ялын оештыру” | мөдир, тәрбияче | май |

### 3.6. Ачык шөгыльләр.

| № | Тема | Җаваплы кеше | Вакыт |
|---|---|---|---|
| 1 | Мәктәпкә әзерлек төркемендә рус теле эшчәнлеген карау | тәрбияче | ноябрь |
| 2 | Ачык ишекләр көне | тәрбияче | январь, март |
| 3 | Мәктәп белән үзара дәресләрдә булу | мөдир, тәрбияче | декабрь |

4 нче бүлек.

**Укыту-тәрбия эшен яхшыртуга юнәлтелгән эшчәнлек.**

**4.1. Педагогик киңәшмәләр.**

| № | Эшләнәчәк эшләр | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | 1.Узган уку елы эшенә анализ.<br>2. Яңа уку елында педагогик коллектив алдында торган төп мәсьәләләр. Яңа уку елына эш планы кабул итү, раслау.<br>3. Тәрбияченең тематик планнарын, дәресләр челтәрен кабул итү, раслау.<br>4. Балалар бакчаларын уку елына әзерләү буенча конкурс йомгаклары. | август | Нургалиева Э.А.<br>Мавлавиева Ф.Г |
| 2. | “Балаларны сәламәтләндерү өчен шартлар булдыру.”<br>1. Традицион булмаган ысуллар белән чыныктыру.<br>2. Физик тәрбиядә гаиләнең роле.<br>3. Балаларның иминлеген һәм сәламәтлеген саклау турында сөйләшү. | ноябрь | Мавлавиева Ф.Г<br>Нургалиева Э.А.<br>Мавлавиева Ф.Г |
| 3. | “Осталык нигезе- тырышлык”.<br>1. Укыту-тәрбия эшенең ярты еллыгына нәтиҗә ясау.<br>2. Балаларның сөйләм телен үстерүдә җырлы, такмаклы уеннарның әһәмияте.<br>3. Дидактик уеннарның баланың логик фикерләү сәләтен үстерүгә булышлыгы. | февраль | Мавлавиева Ф.Г<br>Нургалиева Э.А.<br>Мавлавиева Ф.Г |
| 4. | “2024-2025 нче уку елында эшләнгән эшкә нәтиҗә ясау”.<br>1.Уку елында әшләнгән әшләргә нәтиҗә ясау<br>2. 2023-2024 нче уку елында балаларның сәламәтлеге турында отчет.<br>3. “Эш нәтиҗәләре”- уку елында балаларга белем һәм тәрбия бирү программасының үтәлеше турында тәрбияче отчеты.<br>3. Җәйге чорга сәламәтләндерү эше планын кабул итү. | май | Нургалиева Э.А.<br>Нургалиева Э.А.<br>Мавлавиева Ф.Г<br>Нургалиева Э.А.<br>Мавлавиева Ф.Г |

**4.2. Укыту-тәрбия процессында педагогик контроль.**
**Оператив тикшерү**

| № п/п | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| 1. | Төркемнең яңа уку елына әзерлеген тикшерү. | Сентябрь | Бакча мөдире |
| 2. | Тәрбияченең тематик планнарын, документацияләрен, ата-аналар почмагын һ.б.тикшерү. | Сентябрь | Бакча мөдире |
| 3. | Төркемдә тәрбия һәм белем бирү эшенә контроль ясау. | Ел дәвамында | Бакча мөдире |
| 4. | Балаларның тукландыру графигын контрольдә тоту. | Ел дәвамында | Бакча мөдире |
| 5. | Төркемдә чыныктыру чараларын үткәрүне контрольдә тоту. | Ел дәвамында | Бакча мөдире |
| 6. | Төркемдә культура – гигиена кагыйдәләренең дөрес үтәлешен контрольдә тоту. | Ел дәвамында | Бакча мөдире |
| 7. | Тәрбияченең календарь планнарын вакытында төзүләрен тикшереп тору. | Ел дәвамында | Бакча мөдире |
| 8. | Иртәнге гимнастиканың системалы һәм программа таләпләренә туры китереп үткәрелүен контрольдә тоту. | Ел дәвамында, системалы рәвештә | Бакча мөдире |
| 9. | Педагогик киңәшмәләр, чыгарган карарларның үтәлешен контрольдә тоту. | Ел дәвамында | Бакча мөдире |
| 10. | Балалар иртәләрен, музыкаль күңел ачуларны, физкультура мавыктыргыч уеннарны оештыруны һәм үткәрүне контрольгә алу. | Ел дәвамында | Бакча мөдире |
| 11. | Көндәлек режимның үтәлеше. | Ел дәвамында | Бакча мөдире |
| 12. | Төркемдә әти-әниләр җыелышын оештыруга һәм үткәрүгә контроль | Квартал саен | Бакча мөдире |

## 4.3. Метод почмакта эш.

| № | Эшләнәчәк эшләр | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1 | Стендларны яңарту. Комплекслы-тематик һәм перспектив планнарны яңарту. | сентябрь | Мавлавиева Ф. |
| 2 | Тәрбияченең информацион карталарын тутыру. | октябрь | Мавлавиева Ф. |
| 3 | Туган якның тарихын, милли йолаларын һәм гореф-гадәтләрен өйрәнү буенча материаллар туплау. | ел дәвамында | Мавлавиева Ф. |
| 4 | Методик почмакка күргәзмә материаллар туплау, алу. | ел дәвамында | Нургалиева Э. |
| 5 | Тәрбияви һәм санитария-гигиена темаларына стендлар төзү, яңарту. | даими | Мавлавиева Ф. |
| 6 | Сәнгать шөгыльләре өчен табигый материал, күрсәтмә, кулланма җиһазлар туплау. | даими | Мавлавиева Ф.Г |

## 4.4.Смотр-конкурслар, күргәзмәләр.

| № | Үткәреләчәк мероприятиеләр | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1 | "Яңа уку елына әзерлек". Районара балалар бакчалары арасында конкурс. | август | Нургалиева Э.А. |
| 2 | Рәсем конкурсы "Алтын көз". | сентябрь | Мавлавиева Ф.Г |
| 3 | "Уңыш 2023"- бәйрәменә яшелчә, җиләк-җимештән күргәзмә оештыру. | октябрь | Мавлавиева Ф.Г |
| 4 | "Минем әни иң гүзәле". Фотоконкурс | ноябрь | Мавлавиева Ф.Г |
| 5 | "Сихри участок" – кардан сыннар ясау буенча балалар бакчалары арасында конкурс.<br>"Сихри Кыш"- бәйрәмгә бүлмәләрне бизәү, маскалар ясау. | декабрь | Нургалиева Э.А.<br>Мавлавиева Ф.Г |
| 6 | "Әти белән көчле мин" – рәсем күргәзмәсе<br>Рәсемнәр конкурсы: "Дети России-за мир!" | февраль | Мавлавиева Ф.Г |
| 7 | 8 нче мартка әниләр һәм балалар белән эшләнгән эшләргә конкурс. | март | Мавлавиева Ф.Г |
| 8 | "Иң оста шигырь сөйләүче"- Г.Тукай туган көндә шигырь конкурсы.<br>Г.Тукай әсәрләре буенча конкурс: "Тукай безнең күңелләрдә". | апрель | Мавлавиева Ф.Г |
| 9 | "Җиргә тынычлык кирәк!". Балалар һәм әти-әниләр белән Бөек Җиңүгә багышланган рәсем | май | Мавлавиева Ф.Г |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | конкурсы. | | |
| 10 | “Иң яхшы балалар мәйданчыгы”- район балалар бакчалары арасында конкурс. | май | Мавлавиева Ф.Г |
| 11 | Район, республика күләмендә үткәреләчәк конкурсларда катнашу. | ел буе | Нургалиева Э.А.<br>Мавлавиева Ф.Г |

**4.5. Бәйрәмнәр, күңел ачу кичәләре.**

| № | Үткәреләчәк мероприятиеләр | Вакыт | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1 | Белем бәйрәме. | Сентябрь | Тәрбияче |
| 2 | “Сөмбелә” бәйрәме<br>Өлкәннәр көне | Октябрь | Тәрбияче |
| 3 | Туган көн бәйрәмнәрен уздыру. | Даими | Тәрбияче |
| 4 | “Хуш киләсең, Яңа ел!” | Декабрь | Тәрбияче |
| 5 | Кышкы спорт уеннары ярышы. 1нче класс укучылары белән. | Январь | Тәрбияче |
| 6 | “Ватанны саклаучылар” – этиләр бәйрәме | Февраль | Тәрбияче |
| 7 | “Сөекле әнием!” –әниләр бәйрәме<br>Нәүрүз бәйрәме | Март | Тәрбияче |
| 8 | “Тукай шигырьләре” – шигырь бәйрәме | Апрель | Тәрбияче |
| 9 | “Хуш сөекле бакчабыз!” | Май | Тәрбияче |
| 10 | Күңелле сабантуйлар! | Июнь | Тәрбияче |

5 нче бүлек

## 5.1.Ата-аналар белән эш

| № | Үткәреләчәк мероприятиеләр | Вакыт | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1 | а) Яңа эти-әниләр белән килешүләр төзү. Устав белән таныштыру.<br>б) Әти-әниләргә җыела торган взнос турында аңлату эшләре алып бару.<br>в) Әти-әниләр җыелышы үткәрү.<br>г) Әти-әниләр комитетын сайлау, планын төзү. | Сентябрь | Бакча мөдире<br>Тәрбияче |
| 2 | а) «Көзге сезонда балаларның сәламәтлеген саклау».Әти-әниләр почмагын тулыландыру.<br>б) Территориядәге картайган агачларны кисү буенча эти-әниләрнең ярдәме. | Октябрь | Бакча мөдире<br>Тәрбияче |
| 3 | а) “Юл йөрү кагыйдәләрен беләсезме?”- эти-әниләр өчен консультация. | Ноябрь | Тәрбияче |
| 4 | а) Әти-әниләр җыелышы үткәрү.<br>б) Яңа ел бәйрәмнәрен уздыруда әти-әниләрне җәлеп итү. Ата-аналар комитетының утырышы.<br>в) Әти-әниләрне уен мәйданчыгына кардан сыннар ясау буенча ярдәмгә чакыру. | Декабрь | Бакча мөдире<br>Тәрбияче |
| 5 | а) «Кышкы чорда балаларның сәламәтлеген саклау». Әңгәмә, күчмә папкага информация.<br>б) “Сәламәтлек атналыгы” – ачык ишекләр көне | Январь | Тәрбияче |
| 6 | а) «Әти белән көчле мин!». Рәсем күргәзмәсе<br>б) “Ватанны саклаучылар көне”- бәйрәм иртәсе | Февраль | Тәрбияче |
| 7 | а) «Әниемә бер бүләк!» Балалар рәсемнәреннән күргәзмә.<br>б) Хатын-кызлар бәйрәменә әниләрне чакыру, чәй өстәле әзерләү.<br>в) “Гүзәллек атналыгы”- ачык ишекләр көне | Март | Бакча мөдире<br>Тәрбияче |
| 8 | а) Әти-әниләр почмагында тәрбия темасына күчмә папканы тулыландыру.<br>б) Авыр гаиләләрнең өйләрендә булу, консультацияләр бирү.<br>в) Территорияне җыештыру, өмә уздыру | Апрель | Бакча мөдире<br>Тәрбияче |
| 9 | а) Әти-әниләр җыелышы үткәрү<br>б) Яшелчәләр, чәчәк орлыклары утыртуда эти-әниләрнең ярдәмен оештыру.<br>в) “Хуш сөекле бакчабыз!”- бәйрәм иртәсе | Май | Бакча мөдире<br>Тәрбияче |

## Гомуми әти-әниләр җыелышлары

| № п/п | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| I | Янурыс балалар бакчасының 2024-2025 уку елына алынган бурычлары белән таныштыру. | | |
| 2 | Әти-әниләр комитеты рәисенең узган уку елында эшләнгән эшенә отчетын тыңлау | | |
| 3 | Авылның медсестрасы чыгышы "Грипп һәм аңа каршы вакцина" | | |
| 4 | Әти-әниләр комитетын сайлау | | |
| II | **Тема: "Балагыз әхлаклы булсын..."** | Декабрь | |
| 1 | "Ата-ана әхлаклы булса, бала бәхетле була" | | Бакча мөдире |
| 2 | "Балалар бакчасы һәм гаиләнең бердәмлеге." | | Тәрбияче |
| III | **Тема: "Балалар бакчасы белән гаиләнең бердәмлеге"** | Май | |
| 1 | "Бердәм эшләү нәтиҗәләре" – чыгыш | | Тәрбияче |
| 2 | "Баланың сәламәтлеген бергә ныгытыйк, саклыйк" | | Бакча мөдире |

## "Ачык ишекләр " көне

| № п/п | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| 1 | "Сәламәтлек атналыгы" | Январь | Бакча мөдире, тәрбияче |
| 2 | "Гүзәллек атналыгы" | Март | Тәрбияче |

## Әти-әниләр өчен консультацияләр

| № п/п | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| 1 | "Бала өчен уенчыкның әһәмияте" | Сентябрь | Тәрбияче |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2 | "Татар халкының авыз иҗаты аша балаларның сөйләм телен үстерү" | Октябрь | Тәрбияче |
| 3 | "Балага җәза бирү дөресме?" | Ноябрь | Тәрбияче |
| 4 | "Өйдә рәсем һәм әвәләү шөгыль-ләрен ничек оештырырга" | Февраль | Тәрбияче |
| 5 | "Сезнең балагыз мәктәпкә әзерме?" | Апрель | Тәрбияче |
| 6 | "Кояш, һава һәм су – безнең якын дусларыбыз" | Май | Тәрбияче |

## 5.2. Җәмәгатьчелек һәм спонсорлар белән эш.

| № | Эшләнәчәк эшләр | Вакыт | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1 | Киләсе уку елына ремонт эшләре буенча ҖҮС рәисе белән сөйләшү. | Ел эчендә | Мөдир |
| 2 | ҖҮС утырышларында катнашу | Даими | Мөдир |
| 3 | ҖҮС сессияләрендә, җыеннарында балалар бакчасының эшчәнлеге турында чыгышлар ясау. | План буенча | Мөдир |
| 4 | Район буенча оештырылган өмәләрдә, конкурс, бәйгеләрдә катнашу. | План буенча | Мөдир |

6нчы бүлек

**Административ- хуҗалык эшләре.**

| № п/п | Эшләнәсе эшләр | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|
| 1. | Бакчаны яңа 2024-2025 нче уку елына әзерләү. | Август | Бакча мөдире |
| 2. | Балаларны “электронный детский сад”тан барлау. | Сентябрь | Бакча мөдире |
| 3. | Балалар бакчасы хезмәткәрләренә инструктаж үткәрү, кул куйдырту. | Сентябрь | Бакча мөдире |
| 4. | Ягу системаларын карауны оештыру һәм ягу сезонына әзерләнү. | Сентябрь | Бакча мөдире |
| 5. | Балалар бакчасының санитария-гигиена таләпләренең үтәлешен тикшерү. | Ел дәвамында | Бакча мөдире |
| 6. | Мебель һәм инвентарьларга маркировкалар билгеләү. | Ел башы | Бакча мөдире |
| 7. | Клумбаларга күпъеллык чәчәкләр утыртуны дәвам итү . | Сентябрь | Бакча мөдире<br>Тәрбияче |
| 8. | Балалар бакчасында инвентаризация үткәрү. | План буенча | Бакча мөдире |
| 9. | Яктырту системасыннан һәм судан дөрес һәм экономияле файдалану . | Ел дәвамында | Бакча мөдире |
| 10. | Балалар бакчасы территориясендә оештыру эшләре: куакларны тигезләп кисү, агачларның корыган ботакларын кисү, яңа куаклар утырту, яшелчә һәм җиләк-җимеш бакчасын казу, чүп үләннәреннән чистарту. | Сентябрь<br>Октябрь | Бакча мөдире<br>Тәрбияче<br>Кече тәрбияче |
| 11. | Булдыра алганча куллануга яраксыз хуҗалык инвентарен, савыт-сабаларны яңага алыштыру һәм гамәлдән чыгару. | Ел дәвамында | Бакча мөдире |
| 12. | Техник куркынычсызлык кагыйдәләрен төгәл үтәү. | Ел дәвамында | Бакча мөдире |
| 13. | Отпуска графигын булдыру. | Декабрь | Бакча мөдире |
| 14. | Кыш айларында керү-чыгу юлларын кардан чистартып тору. | Декабрь-март | Кече тәрбияче |
| 15. | Бакчада косметик ремонт эшләрен башкару | Август | Коллектив |

## Балалар бакчасында сәламәтләндерү эше.

| № | Эш төре | Үтәлеш | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1. Оештыру эшләре | | | |
| 1.1 | Көнлек режимны оештыру һәм күзәтү | даими | тәрбияче |
| 1.2 | Физик тәрбия, “сәламәтлек” папкасын тулыландыру | даими | тәрбияче |
| 1.3 | Медицина тикшерүе нәтиҗәләрен һәм авыруларны анализлау | ай саен | тәрбияче |
| 1.4 | “Сәламәтлек” көне үткәрү | даими | тәрбияче |
| 1.5 | - яктылык режимын<br>- $t^0$ режимын<br>- һава режимын<br>- юеш җыештыруны үтәү | даими | мөдир<br>тәрбияче |
| 2. Сәламәтләндерү чаралары | | | |
| 2.1 | Балаларны иртән тикшереп кабул итү | даими | тәрбияче |
| 2.2 | Иртәнге гимнастика ясату | даими | тәрбияче |
| 2.3 | Физкультура дәресләре үткәрү | даими | тәрбияче |
| 2.4 | Саф һавада хәрәкәтле уеннар | даими | тәрбияче |
| 2.5 | Һава, кояш ваннасы алу | даими | тәрбияче |
| 2.6 | Су процедуралары үткәрү | даими | тәрбияче |
| 2.7 | Йокыны оештыру | көн саен | тәрбияче |
| 2.8 | Культура-гигиена күнекмәләре бирү | көн саен | тәрбияче |
| 2.9 | Сәламәтләндерү гимнастикасы<br>Коррекция эшләре ( аю табанлылыкны профилактикалау буенча күнегүләр) | даими | тәрбияче |
| 2.10 | Дәресләр вакытында физкультминуткалар үткәрү | даими | тәрбияче |
| 2.11 | Саф һавада йөрү | даими | тәрбияче |
| 2.12 | Чыныктыру: Су һәм һава белән чыныктыру күнекмәләре бирү | даими | тәрбияче |
| 3. Дәвалау профилактика эше. | | | |
| 3.1 | Профилактика прививкаларын ясау | план буенча | фельдшер |
| 4. Туклануны оештыру | | | |
| 4.1 | Көнгә 4 ашатуны оештыру | көн саен | мөдир |
| 4.2 | Ризыкның саклану срогын карау | даими | пешекче |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4.3 | Тукландыру нормасын үтәү | даими | мөдир |
| 5. Профилактик чаралар | | | |
| 5.1 | Санитар-өйрәтү эше: консультацияләр,әңгәмәләр, семинарлар, лекцияләр | даими | мөдир |
| 5.2 | Балаларның имгәнүен булдырмау буенча чаралар үткәрү:<br>Куркынычсызлык инструкциясен үтәү<br>Балалар белән әңгәмәләр үткәрү<br>Шөгыльләр үткәрү | даими | тәрбияче |
| 5.3 | Йогышлы чирләргә профилактик чаралар:<br>-сарымсак һәм суган куллану | даими | коллектив |
| 5.4 | Спортлы көнел ачулар | айга бер | коллектив |